**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 30 декабрь № 1012

г. Казань

Дәүләт, шул исәптән хәрби, һәм белем бирү эшчәнлегенә дәүләт аккредитациясе булган шәхси мәгариф оешмаларының аспирантлары, адъюнктлары, студентлары һәм курсантлары өчен Татарстан Республикасының махсус дәүләт стипендиясе турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 ел, 29 декабрь, ФЗ-273 нче Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Президентының «Дәүләт, шул исәптән хәрби, һәм белем бирү эшчәнлегенә дәүләт аккредитациясе алган шәхси мәгариф оешмаларының аспирантлары, адъюнктлары, студентлары һәм курсантлары өчен Татарстан Республикасының махсус дәүләт стипендияләрен гамәлгә кую турында» 1998 ел, 3 март, ПУ-168 нче Указы нигезендә һөнәри белем алуда дәүләт ярдәмен тормышка ашыру, яшьләрнең интеллектуаль потенциалын саклау һәм үстерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән түбәндәгеләрне расларга:

Дәүләт, шул исәптән хәрби, һәм белем бирү эшчәнлегенә дәүләт аккредитациясе булган шәхси мәгариф оешмаларының аспирантлары, адъюнктлары, студентлары һәм курсантлары өчен Татарстан Республикасының махсус дәүләт стипендиясе турындагы нигезләмәне;

дәүләт, шул исәптән хәрби, һәм белем бирү эшчәнлегенә дәүләт аккредитациясе булган шәхси мәгариф оешмаларының аспирантлары, адъюнктлары, студентлары һәм курсантлары өчен Татарстан Республикасының махсус дәүләт стипендиясе буенча комиссия составын.

2. Дәүләт, шул исәптән хәрби, һәм белем бирү эшчәнлегенә дәүләт аккредитациясе булган шәхси мәгариф оешмаларының аспирантлары, адъюнктлары, студентлары һәм курсантлары өчен Татарстан Республикасының махсус дәүләт стипендиясен түләү буенча чыгымнар Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының җыелма сметасы исәбеннән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип санарга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары, урта һәм башлангыч һөнәри белем бирүче дәүләт, шул исәптән хәрби, һәм дәүләт аккредитациясе булган дәүләткә карамаган мәгариф учреждениеләре аспирантлары, адъюнктлары, студентлары, курсантлары һәм укучылары өчен Татарстан Республикасының махсус дәүләт стипендиясе турында» 1999 ел, 1 февраль, 35 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары һәм урта һөнәри белем бирүче дәүләт мәгариф учреждениеләре студентлары, аспирантлары һәм укучылары өчен Татарстан Республикасының махсус дәүләт стипендиясе турында» 1999 ел, 1 февраль, 35 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2002 ел, 25 июль, 442 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары һәм урта һөнәри белем бирүче дәүләт мәгариф учреждениеләре студентлары, аспирантлары һәм укучылары өчен Татарстан Республикасының махсус дәүләт стипендиясе турында » 1999 ел, 1 февраль, 35 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт һәм дәүләт аккредитациясе булган дәүләткә карамаган мәгариф учреждениеләре аспирантлары, студентлары һәм укучылары өчен Татарстан Республикасының махсус дәүләт стипендиясе турында, Махсус дәүләт стипендиясе буенча комиссия турындагы нигезләмәләргә һәм Махсус дәүләт стипендиясе буенча комиссия составына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2003 ел, 20 март, 153 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары һәм урта һөнәри белем бирүче дәүләт мәгариф учреждениеләре студентлары, аспирантлары һәм укучылары өчен Татарстан Республикасының махсус дәүләт стипендиясе турында » 1999 ел, 1 февраль, 35 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт һәм дәүләт аккредитациясе булган дәүләткә карамаган мәгариф учреждениеләре аспирантлары, студентлары һәм укучылары өчен Татарстан Республикасының махсус дәүләт стипендиясе турындагы нигезләмәгә өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2003 ел, 3 июнь, 340 нчы карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары һәм урта һөнәри белем бирүче дәүләт мәгариф учреждениеләре студентлары, аспирантлары һәм укучылары өчен Татарстан Республикасының махсус дәүләт стипендиясе турында» 1999 ел, 1 февраль, 35 нче карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 27 декабрь, 645 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары һәм урта һөнәри белем бирүче дәүләт мәгариф учреждениеләре студентлары, аспирантлары һәм укучылары өчен Татарстан Республикасының махсус дәүләт стипендиясе турында» 1999 ел, 1 февраль, 35 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 15 декабрь, 890 нчы карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына

үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 23 ноябрь, 795 нче карарынын 1 һәм 2 нче пунктлары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары, урта һәм башлангыч һөнәри белем бирүче дәүләт, шул исәптән хәрби, мәгариф учреждениеләре студентлары, курсантлары, аспирантлары һәм укучылары өчен Татарстан Республикасының махсус дәүләт стипендиясе турында» 1999 ел, 1 февраль, 35 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 20 октябрь, 873 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары, урта һәм башлангыч һөнәри белем бирүче дәүләт, шул исәптән хәрби, һәм дәүләт аккредитациясе булган дәүләткә карамаган мәгариф учреждениеләре аспирантлары, адъюнктлары, студентлары, курсантлары һәм укучылары өчен Татарстан Республикасының махсус дәүләт стипендиясе турында» 1999 ел, 1 февраль, 35 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 18 июль, 500 нче карары.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Югары, урта һөнәри белем бирү һәм фән бүлегенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\1012.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 30 декабрь, 1012 нче
карары белән расланды

**ДӘҮЛӘТ, ШУЛ ИСӘПТӘН ХӘРБИ, ҺӘМ БЕЛЕМ БИРҮ ЭШЧӘНЛЕГЕНӘ ДӘҮЛӘТ АККРЕДИТАЦИЯСЕ БУЛГАН ШӘХСИ МӘГАРИФ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ АСПИРАНТЛАРЫ, АДЪЮНКТЛАРЫ, СТУДЕНТЛАРЫ ҺӘМ КУРСАНТЛАРЫ ӨЧЕН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МАХСУС ДӘҮЛӘТ СТИПЕНДИЯСЕ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ**

1. Татарстан Республикасының махсус дәүләт стипендиясе (алга таба – махсус стипендия) дәүләт, шул исәптән хәрби, һәм белем бирү эшчәнлегенә дәүләт аккредитациясе булган шәхси мәгариф оешмаларының (алга таба – мәгариф оешмалары) көндезге уку формасындагы аспирантлары, адъюнктлары, студентлары һәм курсантларына (алга таба – укучылар), яхшы укыган, фәнни-гамәли конференцияләрдә һәм предмет олимпиадаларында җиңгән һәм призлы урыннар яулаган өчен, Татарстан Республикасы Президенты указы нигезендә билгеләнә торган күләмдә һәм санда бирелә.

Татарстан Республикасының югары уку йортлары ректорлары советы тәкъдиме буенча махсус стипендия Татарстан Республикасыннан читтә укучыларга яхшы укыган, фәнни-гамәли конференцияләрдә һәм предмет олимпиадаларында җиңгән һәм призлы урыннар яулаган өчен билгеләнә.

2. Махсус стипендияне алуга кандидатлар 2 нче уку елыннан аспирантлар һәм адъюнктлар арасыннан, 3 нче уку елыннан студентлар, курсантлар арасыннан мәгариф оешмаларының гыйльми (педагогик) советы тарафыннан тәкъдим ителә.

Татарстан Республикасының югары уку йортлары ректорлары советы тәкъдиме буенча махсус стипендия укучыларга яхшы укыган, фәнни-гамәли конференцияләрдә һәм предмет олимпиадаларында җиңгән һәм призлы урыннар яулаган өчен, 1 нче уку елыннан аспирантлар, адъюнктлар арасыннан, 2 нче уку елыннан студентлар һәм курсантлар арасыннан билгеләнә.

3. Аспирантлар һәм адъюнктларга – еллык аттестация нәтиҗәләре буенча, студентлар һәм курсантларга – укучыларның арадаш аттестациясе нәтиҗәләре буенча махсус стипендия билгеләү Татарстан Республикасы Президенты указы белән ел саен, 31 декабрьгә кадәр бер уку елына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тәкъдиме буенча, составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расла торган дәүләт, шул исәптән хәрби, һәм белем бирү эшчәнлегенә дәүләт аккредитациясе булган шәхси мәгариф оешмаларының аспирантлары, адъюнктлары, студентлары һәм курсантлары өчен Татарстан Республикасының махсус дәүләт стипендиясе буенча комиссия (алга таба – Комиссия) карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

4. Комиссия ел саен, 1 ноябрьгә кадәр үзе билгеләгән методика нигезендә, мәгариф оешмаларының, Татарстан Республикасының югары уку йортлары ректорлары советының, «Татарстан Республикасы студентлар лигасы» төбәк яшьләр

иҗтимагый оешмасының, Татарстан Республикасы яшь галимнәр һәм белгечләр төбәк яшьләр иҗтимагый хәрәкәтенең тәкъдимнәрен исәпкә алып, өстенлекле юнәлешләр буенча белгечләр әзерләү ихтыяҗыннан чыгып, мәгариф оешмаларының махсус стипендия бирүгә кандидатлар саны квотасын билгели.

5. Мәгариф оешмасының гыйльми (педагогик) советы рәисе имзалаган тәкъдимнамәләрне алган кандидатлар исемлеге, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 6 нчы пунктында каралган мәгълүматларны үз эченә алган документлар мәгариф оешмасы тарафыннан ел саен, 1 сентябрьгә кадәр Комиссиягә җибәрелә.

6. Комиссия махсус стипендия бирүгә кандидатны тәкъдим итү турында карар кабул итү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

а) махсус стипендия бирүгә кандидатлар күрсәтү турында мәгариф оешмаларының гыйльми (педагогик) советлары тәкъдимнамәсе;

б) мәгариф оешмасының гыйльми (педагогик) советы тәкъдимнамәсе буенча кандидатларның еллык яки арадаш аттестация нәтиҗәләре буенча укуның бөтен чорында «бик яхшы» һәм «яхшы» билгеләре булу;

в) укуның бөтен чорында үткәрелгән төбәк, бөтенроссия, халыкара һәм (яки) башка олимпиадаларның, иҗади конкурсларның, һөнәри осталык конкурсларының һәм (яки) укучының укудагы казанышларын билгеләүгә йөз тоткан башка шундый чараларның җиңүчеләре (яулаган урынны күрсәтеп) һәм яки призерлары дипломнары (башка документлар) белән расланган укуда казанышлар булу.

7. Комиссия ел саен, 1 сентябрьдән алып 1 ноябрьгә кадәр әлеге Нигезләмәнең 5 нче пункты нигезендә тапшырылган документларны карап тикшерә һәм махсус стипендия алуга кандидатларны тәкъдим итү турында карар кабул итә.

8. Мәгариф оешмаларының махсус стипендиягә тәкъдим ителгән кандидатлар саны мәгариф оешмаларының махсус стипендия бирүгә кандидатлар квотасыннан арткан очракта, махсус стипендия бирүгә кандидатны тәкъдим итү турында Комиссия карары Комиссия үзе билгеләгән методика буенча гамәлгә ашырыла торган конкурс нигезендә сайлап алу нәтиҗәләре буенча кабул ителә. Кирәк булган очракта, Комиссия үзенең утырышында махсус стипендия бирүгә кандидатларны тыңлауны үткәрә.

9. Тавыш бирүне оештыру һәм махсус стипендия бирү турындагы тәкъдимнәрне карап тикшерү нәтиҗәләрен билгеләү өчен, Комиссия утырышында Комиссия әгъзалары арасыннан өч кешедән торган хисап комиссиясе сайлана.

10 Мәгариф оешмаларының гыйльми (педагогик) советлары тәкъдимнамәсе буенча, чираттагы арадаш аттестациягә керү рөхсәте булмаган очракта, укучыларга махсус стипендия билгеләүдән баш тарту турында карар кабул ителә.

11. Комиссия карарлары утырыш вакытында, Комиссия әгъзаларының кимендә өчтән ике өлеше булганда, утырышта катнашучы Комиссия әгъзалары ачык тавыш бирү юлы белән, тавышларның күпчелеге нигезендә кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, Комиссия рәисе тавышы хәлиткеч санала. Комиссия карарлары барлык Комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана торган беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм утырышны үткәргән көннән 10 эш көне эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертелә.

12. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ел саен, 15 ноябрьгә кадәр махсус стипендия бирүгә кандидатларны тәкъдим итү турындагы Комиссия карарын Татарстан Республикасы Президенты Аппаратына җибәрә.

---

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 30 декабрь, 1012 нче карары белән расланды

## ДӘҮЛӘТ, ШУЛ ИСӘПТӘН ХӘРБИ, ҺӘМ БЕЛЕМ БИРҮ ЭШЧӘНЛЕГЕНӘ ДӘҮЛӘТ АККРЕДИТАЦИЯСЕ БУЛГАН ШӘХСИ МӘГАРИФ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ АСПИРАНТЛАРЫ, АДЪЮНКТЛАРЫ, СТУДЕНТЛАРЫ ҺӘМ КУРСАНТЛАРЫ ӨЧЕН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МАХСУС ДӘҮЛӘТ СТИПЕНДИЯСЕ БУЕНЧА КОМИССИЯ СОСТАВЫ

| | |
|---|---|
| Гафуров Илшат Рәфкать улы | Татарстан Республикасының югары уку йортлары ректорлары советы рәисе, югары һөнәри белем бирүче «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе ректоры, комиссия рәисе (килешү буенча) |
| Гарифуллин Рөстәм Марат улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре һәм спорт министрының беренче урынбасары, комиссия рәисе урынбасары |
| Усанов Владислав Викторович | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының балалар һәм яшьләр оешмалары белән эшләү бүлеге мөдире, комиссиянең җаваплы секретаре |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Кондратьев Андрей Станиславович | «Бердәм Россия» бөтенроссия сәяси партиясенең Татарстан төбәк бүлеге башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Бикеев Игорь Измаилович | югары һөнәри белем бирүче «Икътисад, идарә һәм хокук институты (Казан шәһәре)» шәхси мәгариф учреждениесенең беренче проректоры, фәнни эшчәнлек буенча проректоры, җинаять хокукы һәм процессы кафедрасы профессоры (килешү буенча) |
| Заманов Ренат Илгиз улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының югары, урта һөнәри белем бирү һәм фән бүлеге башлыгы |

| | |
|---|---|
| Маливанов Николай Николаевич | югары һөнәри белем бирүче «А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең белем бирү эшчәнлеге буенча проректоры (килешү буенча) |
| Лоханов Николай Павлович | Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә караган кадрлар, тәрбия эше, һөнәри әзерләү һәм психологик тәмин итү идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Майстренко Владимир Викторович | Казан югары хәрби команда училищесы («Россия Федерациясе Кораллы Көчләренең Гомумгаскәр академиясе» Коры җир гаскәрләренең хәрби уку-укыту фәнни үзәге» югары һөнәри белем бирүче федераль дәүләт казна мәгариф учреждениесенең Хәрби институты (филиалы)) башлыгы, Казан гарнизоны башлыгы (килешү буенча) |
| Поминов Андрей Иванович | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары |
| Җәләлова Анфиса Григорьевна | «Татарстан Республикасының урта һөнәри белем бирүче мәгариф учреждениеләре директорлары советы» коммерциячел булмаган партнерлыгы рәисе, урта һөнәри белем бирүче «Казан педагогика көллияте» дәүләт автоном мәгариф учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Искәндәров Элькин Эльманович | «Татарстан Республикасы студентлар лигасы» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы президенты (килешү буенча) |
| Туманин Виктор Евгеньвич | Татарстан Республикасының яшь галимнәр һәм белгечләр төбәк яшьләр иҗтимагый хәрәкәте башкарма комитеты рәисе (килешү буенча). |

---